# МӘГАРИФ

education

mәǧәrif

просвещение

№4 / 2022

## ТАТАР ТЕЛЕ



Оештыручысы:
**«ТАТМЕДИА»
АКЦИОНЕРЛАР ҖӘМГЫЯТЕ**

МӘГАРИФ education
mağərif просвещение
ТАТАР ТЕЛЕ

ДЕКАБРЬ, 2022 ЕЛ

№ 4

12+

УЧРЕДИТЕЛЬ: **АО «ТАТМЕДИА».**
Телефон редакции: (843) 222-06-09

Адрес издателя:
420097, г.Казань,
ул. Академическая, 2

www.magarif-uku.ru

Создано при поддержке Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям.

Зарегистрирован в Федеральной службе по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций 04.09.2014 г.

**Эл № ФС 77 – 59204**

Периодичность выхода – 1 раз в квартал.

Мнение редакции не всегда совпадает с мнением авторов. Редакция не располагает возможностью выступать ходатаем в официальных организациях. За достоверность рекламных объявлений ответственность несёт рекламодатель.

Почтовый адрес:
**420066, г.Казань, а/я 47**
**e-mail:** magarif@bk.ru

**Адрес:** 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.
«Мәгариф» журналы редакциясе, а/т 47
**E-mail:** magarif@bk.ru
**Сайт:** magarif-uku.ru
«Мәгариф», 2022 ел

Баш мөхәррир: **Таишева С.Н.**
Чыгаручы мөхәррир: **Фаизова Р.Г.**
Әдәби редактор: **Газизова И.М.**
Корректор: **Фәйзуллина Р.Ә.**
Вёрстка:
**Зөфәрова Д.И.**
*Беренче тышлыкта:*
Әгерже районы мәгариф идарәсе оешуга 95 ел. Районда белем бирү системасының тарихын чагылдыручы кластерлар. Фото Р.Фаизова

Журналда кулланылган фотосурәтләр «Мәгариф» редакциясе архивыннан алынды.

*Журнал распространяется бесплатно.*

**ФАИЗОВА Р.** Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк.....................................3

**МӨБАРӘКШИНА А**. Рус телле балалар өчен татар теле дәресләрендә «Шаян ТВ» тапшыруларын куллану үзенчәлекләре.................................12

**ГЫЙНИЯТУЛЛИНА Л., ГАЙНУЛЛИНА Г.** Текст ярдәмендә укучыларның сөйләм телен үстерү юллары..............................................................18

**ЮСУПОВ Р.** Кайчан дөрес сөйли һәм яза башларбыз икән?...................25

**ГАЙФИЕВА А. К** хәрефе һәм **[к]** авазы белән танышу.............................33

**ГАРИФУЛЛИНА Л.** Авыл хикмәтләре.....................................................37

**ӘСӘДУЛЛИНА З.** Исемнәрнең килеш белән төрләнеше........................43

**ЙОСЫПОВА Р.** Белем бәйрәме темасын кабатлау.................................47

**ЮНЫСОВА М., ҖӘЛӘЛОВА Л.** Матурлык һәм батырлык.....................53

**КАСЫЙМОВА З.** Дж.Родариның «Әбинең кошчыклары» әсәрен анализлау..........................................................................................58

**ВӘЛИЕВА Л.** Шагыйрьләр туган як турында .......................................64

**МӨБАРӘКШИНА Г.** Рәвеш төркемчәләре. Охшату-чагыштыру рәвешләре..........................................................................................68

**ӘХМӘДУЛЛИНА А., ШАҺИДУЛЛИНА Р.** Саннарның ясалышы............71

**ГАРИПОВА Р.** Кешеләргә шатлык өләш ................................................74

**ФӘРХЕТДИНОВА Л., ФӘРРАХОВА Р.** Сан төркемчәләре ......................78

**ФӘЙЗУЛЛИНА А.** «Кеше булып кала бел!» темасына Т.Миңнуллинның «Акбур» хикәясе аша бәйләнешле сөйләм үстерү.................................83

**МУЛЛАГАЛИЕВА Г.** Татарстан – минем республикам. Җөмлә кисәкләрен кабатлау ........................................................................................89

**МОРТАЗИНА Л.** Татар әлифбалары авторы..........................................93




01

# ҮТКӘНЕН БЕЛМӘГӘННЕҢ КИЛӘЧӘГЕ ЮК

*Әгерҗе районы мәгариф идарәсе оешуга – 95 ел*



Әгерҗене, һич икеләнмичә, элек-электән тирә-юньгә бер булган мәгърифәтле төбәк дип әйтәбез. Моңа беренче чиратта Иж-Бубый авылының педагог, җәмәгать һәм мәгърифәт эшлекләләре бертуган Габдулла, Гобәйдулла һәм Мөхлисә Бубилар нигез салган мәдрәсәләр сәбәпче. Аларның дан-шөһрәте заманында Россиядә генә түгел, төрки халыклар яшәгән һәр тарафка диярлек мәгълүм була. Укытуның алдынгы алымнары кертелеп,  дөньяви фәннәр белән бергә, рус теле дә өйрәтелә анда. Шуның өстенә чит илдә дөньяви белем алган Гобәйдулла Бубиның физика («Кыйраәте фәнния»), география («Мохтәсар җәгърәфия» – Кыскача география һәм «Җәгърәфия гомумия» – Гомуми география) буенча дәреслекләр булдыру өстендә нәтиҗәле эшләве, Габдулла Бубиның дин һәм татар теленнән дәреслекләр язуы, мәдрәсәне тәмамлаучыларга хәтта хәзерге педучилище дипломнарына тиңләшкән документлар тапшырылуы турында беләбез. Районның бүгенге мәгариф өлкәсенә дә менә шул атаклы мәгърифәт институтына тиңләшеп эшләргә туры килә.

## ТЕРЕ КҮРГӘЗМӘ

Әгерҗе районы мәгариф идарәсе оешуга 95 ел тулуга багышланган чара районда белем бирү системасының тарихын үткән гасырлардан ук бөтен барлыгы белән күз алдына китереп бастырырлык «тере күргәзмә» – кластерлар күрсәтүдән башланып китте. Һәр чор – үзенә бер тарих. Кластерларда 1930–1937 елларда мәҗбүри башлангыч һәм җидееллык белем бирү турындагы законның ни рәвешле тормышка ашырылуын да, халык арасында наданлыкны бетерү өчен көрәшнең ничек кискен торуын да күзалларга була. «Син наданлыкны бетерергә ярдәм итәсең!» «Наданлыктан котылырга!» «Надан кеше ул сукыр кебек, аны һәркайда уңышсызлык һәм бәхетсезлек көтә» кебек плакатлар шул чор сулышы белән өретелгән. Район мәгариф идарәсен Хәйниса Әбелханова җитәкләгән еллар була ул. Укый-яза белмәүчеләрне киметү максатында олы яшьтәгеләр өчен өстәмә сыйныфлар ачылып, 1930 елларга башлангыч мәктәпләр саны 32 гә җиткән, тулы булмаган урта һәм урта мәктәпләр саны да әкренләп артуга барган еллар... Әлеге күргәзмәне эшләү барышында нинди генә реквизитлар тапмаганнар: тарихи документлар, фотографияләр, керосин лампалары, суккан ашъяулыклар кебек көнкүреш кирәк-яраклары, кара савытлары, корыч каләмле ручкалар – барысы да шул чорны күз алдына китереп бастыра.

Дәһшәтле Бөек Ватан сугышы һәм аннан соңгы елларда мәктәпләрнең аяныч хәлләрен язып кына бетерерлекме? Мәктәп тормышының бернинди бизмән күтәрә алмаслык авырлыгы әле ныгып та җитмәгән хатын-кыз укытучылар җилкәсенә төшә... Түз генә! Килгән кунаклар арасындагы өлкән буын вәкилләре, язмышлары шул чорлар белән бәйле ветераннар шактый. Шуңа күрә аларның сабый чаклары, яшьлекләре калган шул елларга «кайтып», күңелләренә уелып калган хатирәләрен яңартулары да бик табигый иде. Бүгенге буын, шөкер, ул михнәтле елларда мәктәп, балалар бакчалары белән бәйле мичкә ягучы, ат караучы, кер юучы кебек һөнәрләрнең булуын ишетеп кенә белә. Кластерларны шәрехләп баручы кыз, һәр чорның үзенчәлегенә басым ясый-ясый, кунакларны «Алга, киләчәккә!» дигәненә – роботлар белән идарә итүче бүгенге көн укучыларына китереп җиткерде. Әйе, еллар уза, буыннар алмаша тора, мәгариф өлкәсенә дә яңадан-яңа техника-технологияләр үтеп керә, бурыч-максатлар да колачлырак була бара. Никита Филиппов (4 нче мәктәп), Гүзәл Насыйрова (1 нче гимназия), Эмилия Даутова һәм Дарья

Прохорова (2 нче мәктәп) кебек Бердәм дәүләт имтиханын 100 әр баллга тапшырган укучыларның гына түгел, һәркайсының киләчәк офыклары якты булачагына ышанасы килә.

## АКСАКАЛЛАР ФИКЕРЕНӘ КОЛАК САЛЫП

– Дөресен генә әйткәндә, 95 еллыкны уздыру фикере, өлкән буын мәгариф ветераннарының, төгәлрәк булсак, 14 ел буе район мәгариф идарәсен җитәкләгән Россия Федерациясе халык мәгарифе отличнигы, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы Шәвкать Рафик улы Халиков белән сөйләшкәннән соң ныгыды. Ул хаклы, чыннан да, безнең системада эшләгән ветераннарның иң өлкән дигәннәре инде әкренләп тугызынчы дистәне ваклап килүчеләр. «90 еллыкны бик матур итеп уздырдыгыз, бер дигән китап чыгардык, 95 еллыкка планнар ничегрәк? Яшерен батырын түгел, биш елдан кем бар да, кем юк...Әллә тәвәккәлисезме?» – дип, мәсьәләне кабыргасы белән куйды ул, – дип сөйли район мәгариф идарәсе җитәкчесе Василә Гарәфетдин кызы Сафиуллина.

Менә шушы сөйләшү 4 сәгать буе барачак кичәгә оеткы сала да инде. Залда барган зур бәйрәм тамашасының башыннан ахырына кадәр үткәнен белмәгәннең киләчәге юк, дигән фикер ярылып ятты. Сәхнәгә бер-бер артлы мөхтәрәм шәхесләр – мәгариф ветераннары күтәрелде, никадәр хатирәләр яңарды, һәркем үзе укыган чордагы укытучыларын, бер гаилә кебек тату булып, аңлашып эшләгән хезмәттәшләрен зур ихтирам-хөрмәт белән искә алды.






Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары Алсу Мөниповна Әсәдуллина шуңа күрә дә әлеге тантананы зур бердәм гаилә бәйрәме дип бәяләде һәм әгерҗелеләргә район мәгариф системасы узган тарихны бөртекләп, кадерләп саклаулары өчен олы рәхмәтен җиткерде.

– Бу бәйрәм ветераннар өчен генә түгел, бүгенге укытучылар, аннан да бигрәк бүгенге мәктәп балалары өчен бик мөһим. Үзебезнең төбәк, мәктәп, илебез тарихын аларга без җиткермәсәк, кем җиткерер?! Бүгенге көндә һәрдаим балаларыбыз янәшәсендә булган укытучыларга, тәрбиячеләргә илебезнең һәм яшь буынның киләчәге хакына зур бурыч йөкләнә, – дип, ул район мәгариф системасына даими ярдәм кулы сузып торган район җитәкчелегенә рәхмәтләрен җиткерде һәм район мәгариф идарәсе җитәкчесе Васыйлә Сафиуллинага, төрле елларда район мәгариф идарәсен җитәкләгән ветераннарга мәгариф һәм фән министры И.Г.Һадиуллинның Рәхмәт хатларын тапшырды.

Район мәгариф идарәсендә озак еллар фидакяр хезмәт куйган белгечләр, методистлар, мәктәп директорлары, тәрбиячеләр, укытучылар шулай ук төрле дәрәҗәдәге мактаулы исемнәргә, бүләкләргә ия булдылар. Зал һәммәсен алкышларга күмде.Үзләре дә ихлас. Әгерҗенең 2нче урта мәктәбендә ярты гасыр гомерен башлангыч сыйныфлар укытуга багышлаган Антонина Ивановна Белова да сүз алып күңелендәгесе белән уртаклашты.

-Укытучы һөнәрен сайлавым белән бәхетлемен. Тормышымны мәктәптән, берсеннән-берсе зирәк укучыларымнан башка күз алдына да китерә алмас идем,- ди тугызынчы дистәсен ваклаучы ветеран-укытучы.

## ЙӨЗӘР ЕЛЛЫ ДИНАСТИЯЛӘР

Педагог хезмәте никадәр җаваплы, авыр булмасын, әти-әниләре, әби-бабалары эзеннән китеп, укытучы һөнәрен дәвам итүче династия вәкилләре дә шактый иде залда. Бу – үзе үк укытучы һөнәренең дәрәҗәсе, абруен күрсәтеп торучы фал.

Иске Эсләктән күренекле Мөслимовлар – Гыйззәтуллиннар династиясенең бу һөнәргә бәйләнгән җеп очы XIX гасырга ук барып тоташа һәм аларның гомуми хезмәт стажы хәтта 1000 (!) елдан артып китә икән. Исәп башы, әлбәттә инде, мәдрәсә мөгаллимнәрендә. Барлый башласаң, араларында мәктәп директорлары, башлангыч сыйныф, биология, химия, математика, татар теле укытучылары да шактый. Татарстан Республикасының атказанган укытучысы Рафаил Равил улы Гыйззәтуллин – шуларның бер вәкиле. Эстафетаны ул әнисе Мөнирә ханымнан алган. Рафаил Равил улының хатыны «РФның



халык мәгарифе отличнигы», «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесенә һәм Н.Крупская исемендәге премиягә ия булган Ферая Изах кызы Гыйззәтуллина – шулай ук зур хөрмәткә лаек мөгаллимә. Буыннан-буынга тапшырылып килүче һөнәрне хәзер аларның уллары Алмаз дәвам итә.

Исәнбай авылындагы Даутовлар – Җәмилевләр дә укытучы исемен горур йөртә. Җәмилевләр династиясенең гомуми стажы 500 ел! Династия башында 1899–1906 елларда Буби мәдрәсәсендә башлангыч мәктәп укытучысы, ә 1907–1929 елларда Россиянең төрле мәктәпләрендә хезмәт куйган Корбангалин Хафизитдин Назметдин улы тора. Аның ике туган сеңлесе Фатима Сәйфелмөлек кызы Даутова 40 елдан артык башлангычларны укыткан. Хезмәт юлын 1938 елны география укытучысы булып башлаган ире Мәхмүт Исмәгыйлович исә сугыш елларында Исәнбай мәктәбе директоры булган. Әнисенең юлыннан китеп, башлангыч сыйныф укытучысы булган кызлары Җәмилева Фәридә Мәхмүт кызы да 40 ел гомерен багышлаган

бу мактаулы хезмәткә. Әлеге тармакның нәсел агачын булдырган кеше дә ул үзе икән. Бүген аларның гаилә традициясен кызлары Лариса белән Ленизa дәвам итә. Исәнбай мәктәбенең технология укытучысы Айгөл Хәмидуллина – шулай ук әлеге нәсел дәвамчысы.

– Үземнең әлеге нәселдән булуым белән горурланып яшим. Гәрчә 19 еллык стажым булса да, кайчандыр үземне укыткан остазларым татар теле белгече Гөлназ Хуҗина, башлангыч сыйныфлар укытучысы Алсу Латыйповалар әле булса миңа зур терәк булып торалар... Тантанада горурланып утырдым, чөнки районның башка мәктәпләре белән рәттән, безнең мәктәпнең эшчәнлегенә дә зур бәя бирелде, – ди ул.

Девәтернә (Девятерня) авылыннан Мөсифуллиннар – Җәмилевләр – Шәйдуллиннар – Тукмановлар династиясендә – егермегә якын педагог. Исәп башы 1903 елга ук барып тоташа, һәм бу династия әлегә укытучылык хезмәтенә гомерләренең 320 елын багышлаган.

Кичкетаң авылында яшәүче Гатиннар турында да бары яхшы сүзләр генә ишетәсең. Аларның бишесе гомер буе авыл балаларын укыткан. Хезмәт кенәгәләренә карасаң, тарих укытучысы Габдулла Гатаулла улы – 46, химик Роза Зия кызы – 50, инглиз һәм немец теле укытучысы Азат Габдулла улы – 25, химик, математик Гөлзар Габдулла кызы 33 ел гомерләрен мәктәп белән бәйләгәннәр. Төпкәрәк төшеп санасаң, династиянең хезмәт стажы 383 елга җыела икән. Шуларның бер вәкиле бу көннәрдә 71 яшен тутыручы Зөлфәт Зөфәр улы белән дә тантанада таныштым.

Әлеге һөнәрнең кыйммәтен элеккеге укучыларыңның рәхмәтләре аша торган саен ныграк аңлыйсың, дигән фикердә ул. Ә аларның инде исәбен ул күптән югалткандыр. Ни дисәң дә, хәзер ул элеккеге укучыларының оныкларын укыта бит.

– Укытучы булгансың икән, иң беренче чиратта син укучыларыңа үрнәк булырга, аларның теләсә кайсы искәрмәс сорауларына җавап бирергә әзер булырга тиешсең. Шәхсән үзем педагогиканы туганыбыз, мәктәп директоры – тарих укытучысы Габдулла Гатауллович һәм биология, анатомия укытучыбыз Замир Габделхакович үрнәгендә сайладым. Алар кебек үк балалар күңеленә очкын салырга теләк уянды. Үземнең дә 6 укучым чит телләр факультетын сайлады. Дөрес, беренче елларда җиңел булмады. Институтны тәмамлап кайтуга, ике 9 нчы сыйныфны бирделәр. Һәркайсында – 40–41 бала. Беренче уку елы тәгәлләнгәч, заводта инженер булып эшләүче туганыбыз тәкъдиме белән җәйге каникул чорында Әлмәттәге

Миннебай газ эшкәртү заводында машинист булып эшләп алдым. Бер ай дигәндә, кулыма укытучының өч айлык хезмәт хакын тоттырдылар. Әллә соң мәктәптән китәргәме икән, дигән икеле-микеле уйлар да керде шул чагында. Алай да 1 сентябрь линейкасына килдем. Шунда бер бала үтерепүтереп бер укытучыны мактапмымактап сөйли. Кем икән бу дим? Шул арада теге бала чәчәкләрен күтәреп миңа таба килде. Сүз минем хакта булып чыкты. Бер ел гына укыттым югыйсә, – дип, үткәннәргә дә кайтып килде 48 ел буе чит телләр укыткан Зөлфәт Зөфәр улы.

Укытучыга булган хөрмәтне бернигә дә алыштырып булмавын әнә шулай күңеленә салып куйган булса кирәк ул. Шул килүдән мәктәптән кире китми егет. Тиздән директор итеп билгеләп, яңа мәктәп салдыру бурычын да йөкләп куялар үзенә.

## МӘКТӘПНЕҢ МАКТАНЫЧЫ – УКУЧЫЛАРЫ

Район мәгариф системасы юбилеена төрле елларда белем алып, бүгенге көндә Татарстанда, Удмуртиядә, Россиянең башка төбәкләрендә җитәкче урыннарда хезмәт куючы күп кенә элеккеге укучылар да кайткан иде. Араларында Халыклар дуслыгы йорты директоры Ирек Шәрипов, «Татмедиа» АҖ җитәкчесенең беренче урынбасары Эльвира Әхмәтова, Түбән Кама шәһәр судының федераль судьясы Илназ Гыйззәтуллин, район сырхауханәсе баш табибыЭдуард Овчинников, ......Искәндәр Җиһангәрәевләрне күрәбез. Үзләрен








кайчандыр укыткан укытучыларына тезләнеп чәчәк тапшыручылар да алар арасыннан иде. Берсе дә буш кул белән кайтмаган. Эльвира Әхмәтова, купшы чәчәкләренә кушып, үзе иҗат иткән җырларын багышлады якташларына. Танылган җырчы Гүзәлия башкаруындагы ул җырларны әгерҗелеләрнең «үзебезнең Кырынды кызы Эльвира язган» дип аеруча дулкынланып тыңлавы аңлашыла. Туган ягыннан илһам алып лирик шигырьләр иҗат итүче шагыйрәнең сүзләренә бүгенге көндә дистәләгән җырлар язылуын һәм аларны Татарстан һәм Башкортстанның танылган җырчылары бик теләп башкаруын тамашачы белеп тора.

«Тормыш имтиханнарын да «5»ле билгеләренә биргәнбез икән, монда безне укыткан укытучының роле бәяләп бетергесез, – дип, Эльвира Фәнисовна укытучыларга тирән ихтирамын белдерде.

Юбилей уңаеннан зур концерт буларак игълан ителгән кичәдә кемнәр генә күтәрелмәде сәхнәгә. Район мәдәният сарае сәнгать осталары, укытучылар, тәрбиячеләрнең чыгышлары тотты сәхнәне. Актаныштан килгән «Агыйдел» дәүләт җыр һәм бию ансамбле белән беррәттән, үзләренең җыр-моңнары белән шатландырдылар әгерҗелеләр. Бәйрәм кунаклары коллегалары белән ихлас аралашудан, мәгариф системасы хезмәткәрләренең хезмәтенә бирелгән югары бәядән, күрсәтелгән хөрмәттән күңелләре булып, шат күңел белән Әгерҗе районы мәгариф системасының 100 еллык юбилеенда очрашырга сүз куешып саубуллаштылар.

**Расиха ФАИЗОВА**

*Автор фотолары*